КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 17 июль г.Казань № 500

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибен һәм дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибен һәм дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасын раслау турында» 2013 ел, 1 июнь, 376 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләре (хезмәтләре) башкаруга (күрсәтүгә) чыгым нормативларын исәпләү тәртибен һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләренең дәүләт эшләрен башкаручы хезмәткәрләренең норматив санын исәпләү методикасын раслау турында»;

1 пунктның икенче абзацында «дәүләт эшләрен башкаруга» сүзләрен «дәүләт эшләре (хезмәтләре) башкаруга (күрсәтүгә)» сүзләренә алмаштырырга;

карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы

Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгына, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенә, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары белән исемлекләре расланган дәүләт хезмәтләренең авырлыгы нормативларын раслауны һәм алга таба яңадан карауны Методика нигезендә тәэмин итәргә».»;

карарның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карарына үзгәреш кертү һәм Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан башкарыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт эшләре исемлеген раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 10 декабрь, 1009 нчы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары» сүзләренә алмаштырырга;

карарга түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4. Әлеге карар дәүләт эшләре (хезмәтләре) башкаруга (күрсәтүгә) чыгым нормативларын исәпләүнең бүтән тәртибе расланмаган Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләренә тарала.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт учреждениеләре тарафыннан дәүләт эшләрен башкаруга чыгымнар нормативларын хисаплап чыгару тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән);

әлеге карар белән расланган Дәүләт эшләрен башкаручы Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең норматив санын хисаплап чыгару методикасында:

1.1 пунктта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан күрсәтелә һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре исемлеге турында» 2009 ел, 24 апрель, 271 нче карарына үзгәреш кертү һәм Дәүләт

учреждениеләре, башка юридик затлар тарафыннан башкарыла һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт эшләре исемлеген раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 10 декабрь, 1009 нчы карары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының учреждениеләре төрләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре арасында дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә һәм башкарыла торган һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган дәүләт хезмәтләре һәм эшләренең якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары» сүзләренә алмаштырырга;

2 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 нче таблица

Ярдәмче (булышлык күрсәтүче) һәм хезмәт күрсәтүче бүлекчәләр хезмәткәрләренең сан нормативлары

| Функция исеме | Бәяләү параметры | Сан нормативы | Бүлекчә төре | |
|---|---|---|---|---|
| | | | ярдәмче (булышлык күрсәтүче) | хезмәт күрсәтүче |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Эш башкару (канцелярия һ.б.ш.) | Бер елга керүче хатлар (йөкләмәләр) саны | 5 000 хатка 1 ставка | + | |
| Бинаны карап тоту | бинаның гомуми мәйданы (норматив) | 650 кв.метр бүлмәгә 1 җыештыручы ставкасы | | + |
| | бинаның гомуми мәйданы (норматив) | 10 000 кв.метрга 3,33 слесарь-сантехник ставкасы | | + |
| | бинаның гомуми мәйданы (норматив) | 10 000 кв.метрга 3,33 электрик ставкасы | | + |
| | бинаның гомуми мәйданы (норматив) | 10 000 кв.метрга бинага агымдагы ремонт буенча 3,33 эшче ставкасы | | + |
| | бинаның | 3 630 кв.метр | | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| | гомуми мәйданы (норматив) | йорт яны территориясенә 1 җыештыручы ставкасы | | |
| Матди-техник тәэмин итү | хезмәткәрләр саны | 250 хезмәткәргә 1 ставка | | + |
| Кадрлар белән идарә | хезмәткәрләр саны | 100 хезмәткәргә 1 ставка | + | |
| Бухгалтер хисабы | хезмәткәрләр саны | 145 хезмәткәргә 1 ставка | + | |
| | | 1 баш хисапчы ставкасы | + | |
| | | Физик затлар белән 1000 подряд шартнамәсенә 1 хисапчы ставкасы | + | |
| Вәкаләтле органнар аша үзәкләштерелгән сатып алуларны файдаланмаганда сатып алуларны гамәлгә ашыру | шартнамәләр саны | 1 000 шартнамәгә 1 ставка | + | |
| Челтәр администрацияләүе | компьютер техникасы белән җиһазландырылган эш урыннары саны | 48 компьютерга 1 ставка | + | |
| Транспорт чарасы белән идарә итү | норматив хокукый актлар белән билгеләнгән автомобильләр саны лимиты лимит | 1 автомобильгә 1 йөртүче ставкасы | | + |
| Биналарны, бүлмәләрне саклау | постлар саны | Төп персонал эшләмәгән вакытта эшләгәндә 1 постка 2,8 ставка, төп персонал эшләгән вакытта эшләгәндә 1 постка 2 ставка | | + |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Килүчеләрнең өс киемен һәм башка вак әйберләрен кабул итү, саклау һәм бирү (гардероб бүлмәсе булган музейлар, библио-текалар өчен) | елга эш көн-нәре саны | гардеробчының 0,6 ставкасы | | + |
| Оешмаларда җи-тештерүдә трав-малар алу, һөнәри һәм җитештерү белән бәйле авы-руларны кисәтү буенча эшне оеш-тыру (хезмәтне саклау) | авыр һәм за-рарлары хезмәт шартлары бе-лән бәйле эш-ләрдә эшләүче хезмәткәрләр саны | 100 хезмәткәргә куркынычсызлык техникасы буенча белгечнең 0,13 ставкасы | +». | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин